**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 сентябрь № 716

г. Казань

2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар планын («юл картасын») раслау турында

«Инвалидлар хокуклары турындагы конвенция ратификацияләнүгә бәйле рәвештә, инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 1 декабрь, ФЗ-419 нчы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Билгеләнгән эшчәнлек өлкәләрендә инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан әзерләү тәртибе һәм вакытлары турында» 2015 ел, 17 июнь, 599 нчы карарны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләрен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар планын («юл картасын») (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Чаралар планын тормышка ашыру тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һәм чикләрендә башкарыла, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына (алга таба – Чаралар планын тормышка ашыруда катнашучылар),

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Чаралар планын тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

4. Чаралар планын тормышка ашыруда катнашучыларга, хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр чагыштырма мәгълүмат әзерләү максатларында, ел саен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү, әлеге мәгънәләргә ирешү өчен тормышка ашырылган чараларны үтәү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшырырга.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, инвалидлар иҗтимагый оешмаларына Чаралар планын тормышка ашыруда катнашырга тәкъдим итәргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\716.doc